Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге
Иске Кощаково авылының Болын, Кояшлы, Чәчәкле, Үзәк урамнары
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

19 декабрь, 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Иске Кощаково авылының Болын, Кояшлы, Чәчәкле, Үзәк урамнарында яшәүчеләрнең 2021 елның 19 декабрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 246 (ике йөз кырык алты).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 128 (йөз егерме сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 128 (йөз егерме сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2022 елда Иске Кощаково авылының Болын, Кояшлы, Чәчәкле, Үзәк урамнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү »

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова